# КОТЛЫ БУЛСЫН САБАНТУЙ!

*сүзләре – Равил Гөзәиров, көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Яктырып янсын йолдызлар
   Туган илем күгендә!
   Тырыш хезмәт, саф мәхәббәт
   Булсын безнең күңелдә!

      Җәйнең матур көннәрендә
      Килә безгә ямьле туй!
      Куандырып бар халыкны
      Котлы булсын сабантуй!

2. Яңгырасын сабантуйда
   Дәртле бию көйләре,
   Җилкендерсен күңелләрне
   Тальян гармун телләре!

      Биесәк тә, җырласак та,
      Килешеп тора безгә.
      Сабантуйдан сабый туйлар
      Күбәйсен иде көзгә!

3. Уртага чык, батыр егет,
   Күрсәт батырлыгыңны!
   Япь-яшь кызлар гашыйк булсын,
   Күреп матурлыгыңны!

      Хезмәттә дә, сәнгатьтә дә
      Алдынгы безнең яшьләр.
      Сабантуйларда җиңәрлек
      Бар әле бездә көчләр!

4. Сабантуйларны үткәрик
   Дуслыкта, бердәмлектә.
   Тугандашлар һәм кардәшләр
   Яшәсен күркәмлектә!

      Җәйнең матур көннәрендә
      Килә безгә ямьле туй!
      Куандырып бар халыкны
      Котлы булсын сабантуй!

**Славься, Сабантуй!**

Песня посвящена татарскому национальному празднику – празднику Сабантуй, отмечаемому по окончании посевных работ.

*Позади уж посевная.*
*Веселись, пляши, ликуй!*
*Землю светом озаряя,*
*К нам приходит Сабантуй!*